
# Уфа ни өчен матур?

Нәби Дәүли сүзләре




Бе - ләм, дус - ка - ем,
бе - ләм сер - лә - рен:
мин си - нең бе - лән
йө - рим у - рам - да,
си - нең күз - лә - рең
rit.
ми - ңа ел - ма - я.
f
Ка - ра - саң ми - ңа,
3
ел - май - саң ми - ңа,
3
f




1977

Уфа каласы ни өчен матур?
Беләм, дускаем, беләм серләрен:
Мин синең белән йөрим урамда,
Синең күзләрең миңа елмая.

К у ш ы м т а:

Карасаң миңа,
Елмайсаң миңа,
Син дә бик матур,
Уфа да матур,
Бик матур дөнья!

Таудан тауларга кояш күченә,
Сиңа да миңа карый шикелле.
Салават батыр корыч атында
Сине дә мине саклый шикелле.

К у ш ы м т а.

Нинди шәһәрләр җирдә күрмәдем,
Булмады минем кайда йөргәнем.
Уфа дисәләр, сине сагынам,
Уфа дисәләр, яна йөрәгем.

К у ш ы м т а.

Очраштык бүген синең калада,
Кирәк түгел лә мактап сөйләргә.
Син дә эндәшмә, мин дә эндәшмим,
Уфаның яме синең күзләрдә.

К у ш ы м т а.